ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
27.06.2024

**К А Р А Р**
№ 583

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе турында» 2017 елның 15 маендагы 1199 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе турында» 2017 елның 15 маендагы 1199 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2 Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына, Биектау районы Башлыгының карарларына һәм күрсәтмәләренә, Биектау муниципаль районы уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин